ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

20 июнь, 2017 ел № 17/9

Шәһәр Советының 2015 елның 28 декабрендәге 5/7 санлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә автомобиль һәм гомуми файдаланудагы шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар йөртүне оештыру Тәртибен раслау турында

Пассажирлар йөртүдә шәһәр халкының ихтыяҗларын тәэмин итү максатында һәм 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсе, 2015 елның 13 июлендәге «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар һәм багажны регуляр йөртүне оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 220-ФЗ санлы Федераль закон, шәһәр Уставының 28 маддәсе нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2015 елның 28 декабрендәге 5/7 санлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә автомобиль һәм гомуми файдаланудагы шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар йөртүне оештыру Тәртибенә 9 пунктның 2 пунктчасын яңа редакциядә бәян итеп үзгәрешләр кертергә:

«2) муниципаль норматив хокукый акт белән билгеләнгән тәртип нигезендә төзелгән мондый маршрутта пассажирлар агымын тикшерү акты.».

2. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының шәһәр төзелеше, шәһәр инфраструктурасын һәм торак-коммуналь хуҗалыкны үстерү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев